**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 ел, 24 сентябрь** **№ 97**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмә хакында” 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 4нче сентябрендәге 64нче номерлы карары белән расланган “Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, съездда (конференция) яисә башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләре гомуми җыелышында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; муниципаль берәмлеге исеменнән оешма оештыручы һәм мунципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлары нигезендә оешманың идарә органнарында һәм ревизия

комиссиясендә оештыручы (акционер, катнашучы) булган муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш; федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк ур., 1нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клубная ур., 14нче йорт,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге Советы рәисе И.Х. Шиһабиев